**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 17 август № 568

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 26 гыйнвар, 20 нче; 2007 ел, 28 апрель, 149 нчы; 2008 ел, 28 гыйнвар, 38 нче; 2008 ел, 25 июль, 534 нче; 2009 ел, 5 март, 125 нче; 2009 ел, 8 май, 283 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1033 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 533 нче; 2012 ел, 10 март, 205 нче; 2012 ел, 9 июнь, 503 нче; 2013 ел, 18 март, 175 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 946 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 254 нче, 2014 ел, 1 ноябрь, 842 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 736 нчы; 2016 ел, 23 март, 157 нче; 2016 ел, 28 июль, 523 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турындагы нигезләмәдә бишенче бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.5 нче пункт өстәргә:


«5.5. Министр урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм аларның хезмәткәрләре эшчәнлегенә нәтиҗәлелеген бәяләү аларның исемлекләре министр боерыгы белән раслана торган төп нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү нәтиҗәләре нигезендә башкарыла.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2005 ел, 6 июль, 316 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 17 август, 568 нче
карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы структурасы**




---